**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**МӘЛӘКӘС АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ**

# КАРАР

«19» октябрь 2016 ел № 20

ТР Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесенең 2015 елның 8 декабрендәге
20 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2013-2020 елларда юл хәрәкәте иминлеген арттыру» федераль максатчан программасы концепциясен раслау турында» 27.10.2012 ел, № 1995-р күрсәтмәсен гамәлгә ашыру максатында

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең 2015 елның 8 декабрендәге 20 номерлы карары белән расланган «Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлегендә 2015-2017 елларга юл хәрәкәте иминлеге» программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Программа паспортының «Финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» бүлеген яңа редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| Финанслау күләмнәре һәм чыганаклар<br>Финанслау күләмнәре һәм чыганаклар | Программаны финанслауның гомуми күләме 320 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>- район бюджеты һәм район авыл җирлеге бюджеты акчалары хисабына 220 мең сум |

1.2. «2015-2017 елларга ТР Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлегендә юл хәрәкәте иминлеге» программасының 3 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:
3. Программаны финанслау.
Программаны финанслауның гомуми күләме 320 мең сум тәшкил итә. Финанслауның күрсәтелгән күләмнәре тиешле финанс елына бюджетлар формалаштырганда төгәлләштерелергә тиеш.
1.2. Мәләкәс авыл җирлеге буенча 2015-2017 елларга юл хәрәкәте иминлеген арттыру программасын яңа редакциядә бәян итәргә:
2. Әлеге карарны районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.
3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе И.Н. Кузнецова